ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль, 2018 ел № 23/12

Коррупциягә каршы тору буенча Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 2017 елның 03 апрелендәге «Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатында Россия Федерациясенең аерым законнарына үзгәрешләр кенртү турында» 64- ФЗ санлы Федераль законына, Татарстан Республикасының 2017 елның 19 июлендәге «Муниципаль вазыйфа яйсә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яйсә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 56-ЗРТ санлы Законы, Татарстан Республикасының 2017 елның 19 июлендәге «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 57-ЗРТ санлы Законы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

Шәһәр Советының 2016 елның 07 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында

Нигезнамәне раслау турында» 7/17 санлы Карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына рәсми бастыруга бирү Тәртибен раслау турында»;

2) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында Нигезнамә»нең 1 нче кушымтасын гамәлдән чыккан дип танырга;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына рәсми бастыруга бирү Тәртибенең 2 пункты, 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, оешмаларның устав (тупланма) капиталында, пайларда өлешләр сатып алган очракта, алыш-бирешнең гомуми суммасы муниципаль вазыйфа биләүче затның һәм аның иренең (хатынының) хисап бирү вакытына кадәр өч ел эчендәге уртак керемнәреннән артып китсә, алыш-биреш ясау чыгымнары хакында белешмә.».

2. Шәһәр Советының 2016 елның 07 апрелендәге «Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясе турында» 7/19 санлы Карарын гамәлдән чыккан дип танырга, «Челнинские известия» газетасының 2016 елның 11 маендагы 33 санында бастырылган.

3. Шәһәр Советының 2016 елның 07 апрелендәге «Вазыйфаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү хакында хәбәр итү тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында» 7/18 санлы Карарында түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне «№1» тамгасы белән тулыландырырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге 2 өлешне өстәргә:

«2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен

үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы комиссиясе турында Нигезнамәне 2 кушымтала каралганча расларга», әлеге Карарның 1 кушымтасына нигезләне ;

3) түбәндәге эчтәлектәге 3 өлешне өстәргә:

«3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы комиссиясе составын 3 кушымтада карлганча расларга», әлеге Карарның 1 кушымтасына нигезләнеп

4) 2 өлешне 4 өлеш белән тулыландырырга;

5) мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну турында хәбәр итү хакындагы Нигезнамәнең 4 пунтында «Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы комиссиясе» сүзләренә алыштырырга.

4. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге шәһәр Советы депутатлары статусы турында Нигезнамәнең (Шәһәр Советының 2016 елның 07 апрелендәге 7/20 санлы Карары редакциясендә) 17 маддәсе, 1 өлеше, 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) гамәлдәге законнар нигезендә ел саен, хисап елы чорыннан килгән елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрен тапшырырга тиеш.».

5. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ